Түбән Үрәс авыл җирлеге Советы

КАРАР

28 январь 2022 ел №2

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Түбән Үрәс авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге Советы

К А Р А Р  Б И Р Д Е :

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Түбән Үрәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» Түбән Үрәс авыл җирлеге Советының 2014 елның 27 гыйнварындагы 2 номерлы карары (2016 елның 16 декабрендәге 31 номерлы, 2018 елның 22 июнендәге 18 номерлы, 2019 елның 20 февралендәге 4 номерлы, 2019 елның 26 августындагы 14 номерлы, 2021 елның 09 июнендәге 10 номерлы, 2021 елның 23 нояберындәге 26 номерлы Түбән Үрәс авыл җирлеге Советы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Түбән Үрәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең «Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә», 18.1 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

«18. 1. Җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1 000 кв.м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлегенең максималь күләме – 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы Р. Х. Шамеев